ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г.Казань Боерык

12.12.2019 № 393-од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 нче июненнән 146-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 16 июнендәге 834 номерлы карары чыгу һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 2 ноябрендәге 310 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында”гы карары үз көчен югалту белән бәйле рәвештә, б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының (алга таба-Дәүләт комитеты) 2018 елның 7 нче июненнән 146-од номерлы “Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламенты турында”гы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен

күрсәтүнең Административ регламентына (Дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә) үзгәрешләр кертергә.

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф.С.Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 нче июненнән 146-од номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 12нче декабреннән 393-од номерлы боерыгы редакциясендә)

**Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү өчен рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты.**

## 1. Гомуми кагыйдәләр.

1.1. Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү өчен рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент), дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар - физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән күрсәтелә ( алга таба – Комитет).

1.3.1. Комитетның урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Комитетның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Гаризаларны кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Иҗтимагый транспорт белән “Татарстан” тукталышына кадәр :

автобуслар № 1, 31, 53, 54, 6, 71;

троллейбуслар №3, 5;

“Ахтямов” тукталышына кадәр :

автобуслар № 23,5, 56, 68, 71, 72.

Керү шәхесне раслый торган документ буенча.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аның барышы турында мәгълүмат бирү Биотөрлелек бүлеге (алга таба – Бүлек) белән башкарыла. Телефон: (843) 211-70-78.

1.3.3. Комитетның мәгълүмати-телекомммуникатив “Интернет” челтәрендә, “Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестры”дәүләт мәгълүмати системасына кероә торган, рәсми сайт адресы http://www.ojm.tatar.ru, электрон почта адресы: ojm@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) мәгълүмати-телекомммуникатив “Интернет” челтәре аша:

-Комитетның рәсми сайтындаhttp://www.ojm.tatar.ru;

-Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

-Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

2) Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/) һәм Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.gosuslugi.ru).

3) Комитетка телдән мөрәҗәгать итеп (телефон аша (843)211-70-78 яки шәхси (102 кабинет));

4) Комитетка язмача мөрәҗәгать итеп (шул санда ojm@tatar.ru рәсми электрон почтага җибәрелгән электрон документ рәвешендә).

5) Комитетның биналарында дәүләт хезмәте турында турыдан-туры күреп һәм текстлы мәгълүмат булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә.

1.3.5. Комитетның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, электрон почтасы, Комитетның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Комитетның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла һәм үз эченә дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 нче пунктларда күрсәтелгән мәгълүматны ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге актлар белән җайга салына:

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба –РФ ШтК);

14.03.1995 елдан 33-ФЗ номерлы “Аерым саклана торган табигый территорияләр турында”гы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 20.03.1995, №12, 1024 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып)(алга таба - 33-ФЗ номерлы Федераль закон);

27.07.2010 елдан № 210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

07.05.2012 елдан 601 номерлы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы (алга таба – 601 нче Боерык);

19.02.2015 елдан 117/пр номерлы “Төзү рөхсәтнамәсен һәм объектны

файдалануга кертү өчен рөхсәтнамә формасын раслау турында”гы Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы (алга таба -117/пр боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 2015, 13 апрель, бастыру номеры 0001201504130006);

02.11.2010 елдан “Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгешләр кертү турында ”гы 880 номерлы Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карары (алга таба –ТРМК 880 номерлы карары)(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46,2144 ст., кертелгән үзгәрешләр белән);

27.09.2017 елдан 729 номерлы “ төзү рөхсәтнамәсе һәм файдалануга кертүгә рөхсәтнамә бирү өчен кирәкле документларны, электрон формада юнәлтү турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән (Татарстан Республикасының законнар җыентыгы, 20.10.2017, № 78 кертелгән үзгәрешләрне истә тотып)( алга таба- 729 номерлы Карар);

15.12.2017 елдан 996 номерлы “Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары ( алга таба – Комитет турында Кагыйдәнамә) (Татарстан Республикасының законнар җыентыгы, 2017, № 95, 3544 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып).

1.5. Бу регламентта киләсе атамалар һәм билгеләмәләр кулланыла:

региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының карарлары белән, тулысынча яки өлешчә хуҗалык файдалануыннан алынган һәм алар өчен билгеләнгән махсус саклау режимы урнаштырылган, аеруча табигать саклау, фәнни, мәдәни, эстетик, ял итү һәм сәламәтлекне саклау әһәмиятенә ия булган, табигать комплекслары һәм объектлары урнашкан җир бүлемтеге, су өсте һәм аларның өстендәге һава киңлеге.

капиталь төзелеш объекты – вакытлы корылмалардан, киосклардан, навеслардан һәм башка шундый корылмалардан кала,төзелеше тәмамланган бина, корылма, объектлар (алга таба - төзелеп бетмәгән объектлар).

линияле объектлар – электр үткәрү чыбыгы, элемтә чыбыгы (шул исәптән линияле-кабель корылмалар), торбалар, автомобиль юллары, тимер юл чыбыклары һәм башка шундый корылмалар;

кызыл линия – линия, алар обозначают булган, ният ителгән (үзгәрә торган, кабат ясала торган) гомуми файдалану территория чикләре һәм (яки) линияле объектлар урнашкан һәм (яки) линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән территория чикләре;

төзү – биналарны, корылмаларны булдыру (шул исәптән капиталь төзелеш объектларын алып ташлаган урында);

капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү (линия объектларыннан

кала) –капиталь төзелеш объектының, аның өлешләренең (биеклек, күп катлылык, мәйданы, күләме), шул исәптән капиталь төзелеш объектын кушып төзү, үзгәртеп кору, киңәйтү ә шулай ук, шундый конструкцияләрнең аерым элементларын шундый ук яки мондый конструкцияләрнең күрсәткечләрен яхшыртучы башка элементларга алыштырудан һәм (яки) күрсәтелгән элементларны яңадан торгызудан кала, капиталь төзелеш объектының тотып торучы төзелеш конструкцияләрен алыштыру һәм (яки) торгызу параметрларын үзгәртү;

линия объектларын реконструкцияләү - сыйныфын, дәрәҗәсен һәм (яки) мондый объектларның башта билгеләнгән функцияләрен(егәрлек, йөк күтәрү һәм башкалар) үзгәртүгә китерүче яки мондый объектларның чыгару сызыклары чикләрен һәм (яки) саклау зоналарын үзгәртүне таләп итүче,линия объектларының яки аларның кишәрлекләренең (өлешләренең)параметрларын үзгәртү;

капиталь төзелеш объектларына капиталь ремонт ясау ( линияле объектлардан кала) –тотып торучы төзелеш конструкцияләреннән кала, капиталь төзелеш объектларының төзелеш конструкцияләрен яки мондый конструкцияләрнең элементларын алыштыру һәм (яки) яңадан торгызу,инженер-техник тәэмин итү системаларын һәм капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең яки аларның элементларын алыштыру һәм (яки) яңадан торгызу, ә шулай ук капиталь төзелеш объектының тотып торучы төзелеш конструкцияләренең аерым элементларын шундый ук яки мондый конструкцияләрнең күрсәткечләрен яхшыртучы башка элементларга алыштыру һәм (яки) күрсәтелгән элементларны яңадан торгызу;

линия объектларына капиталь ремонт ясау - сыйныфын, дәрәҗәсен һәм (яки) мондый объектларның башта билгеләнгән функцияләрен(егәрлек, йөк күтәрү һәм башкалар) үзгәртми торган яки мондый объектларның чыгару сызыклары чикләрен һәм (яки) саклау зоналарын үзгәртүне таләп итми торган, линия объектларының яки аларның кишәрлекләренең (өлешләренең) параметрларын үзгәртү;

инженерлык тикшеренүләре - территорияләрне һәм аның чикләрендәге җирләрне рациональ һәм һәвефсез файдалану максаты белән, техноген йогынтысының табигый шартларын һәм факторларын өйрәнү, территориаль планлаштыру һәм архитектура-төзелеш проектлары өчен кирәкле материалларны нигезләү буенча мәгълүматларны әзерләү;

төзүче – үзенеке булган җир кишәрлегендә яисә башка хокук иясенең җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, аларны капиталь ремонтлауны, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, аларны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өчен проект документларын әзерләүне тәэмин итүче (бюджет инвестицияләрен дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектларына гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), Атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, Галәм эшчәнлеге буенча “Роскосмос” дәүләт корпорациясе, дәүләти бюджетныкы булмаган фондларның идарә органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән очракларда килешүләр

нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшырган) физик яки юридик зат;

техник хата - дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан ясалган һәм документка кертелгән мәгълүматларның(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе), алар нигезендә мәгълүматлар кертелгән документларга тәңгәл килмәвенә китергән хата(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ераклашкан эш урыны – муниципаль районнарның авылларында гаризачыларга мәгълүмат бирү, документларны кабул итү һәм бирү тәрәзәсе.

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза астында ( алга таба – гариза) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорау күз алдында тотыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 пункты). Тәкъдим итиелгән гариза формалары әлеге Регламентның 1, 2 нче кушымтасында бирелгән.

## 2. **Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты**

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү өчен рөхсәтнамә бирү | РФ ШтК 51 ст. 5 б. , 996 нчы карар белән расланган Кагыйдәнамә |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | 996 нчы карар белән расланган Кагыйдәнамә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Төзү рөхсәтнамәсе;<br>Төзү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу срогын озайту;<br>Төзү рөхсәтнамәсенә үзгәрешләр кертү;<br>Төзү рөхсәтнамәсен бирүдән баш тарту турында белдерү;<br>Төзү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында белдерү;<br>Төзү рөхсәтнамәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында белдерү; | РФ ШтК 51 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать | 1. Төзү рөхсәтнамәсен бирү яки төзү рөхсәтнамәсен бирүдән баш тарту (төзү рөхсәтнамәсенә үзгәрешләр кертү) процедурасының тормышка ашыру вакыты, төзү рөхсәтнамәсен бирү (төзү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайту) турында гаризаны теркәгәннән соң, 5 көн | РФ ШтК 51 ст. 11 п. |

| | | |
|---|---|---|
| итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты. | тәшкил итә.<br>2. Төзү рөхсәтнамәсенә үзгәрешләр кертү яки төзү рөхсәтнамәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту процедурасының тормышка ашыру вакыты, гариза бирүчедән яки төзүчедән, аларга җир бүлемтекләренә хокук күчү, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы булу, җир бүлемтеге оештырылу турында белдерүне теркәгәннән соң, 5 көн тәшкил итә.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.<br>Законда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка | Капиталь төзелеш объектын төзү,реконструкцияләү рөхсәтнамәсен бирү турында гариза.<br>Капиталь төзелеш объектын төзү/реконструкцияләү рөхсәтнамәсеснең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза;<br>Аларга карата РФ ШтК белән туры килеп, төзү рөхсәтнамәсе бирелгән җир бүлемтекләренә хокук күчү турында, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы булу турында, берләштерү, бүлү, бүлешү, бүлеп бирү ысулы белән җир бүлемтеге оештырылу турында белдерү. | РФ ШтК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге,гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе. | Гариза кулдан, басма ысул белән яки компьютер кулланып тутырыла, һәм мөһере булганда, гариза бирүченең мөһере белән раслана, мөрәҗәгать итүче белән (аның вәкаләтле вәкиле) шәхсән яисә почта аша Комитет адресына җибәрелә.<br>2.Капиталь төзелеш объектын төзү/реконструкцияләү рөхсәтнамәсенә киләсе документлар кушыла:<br>1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитутны билгеләү турында килешү, гавами сервитутны билгеләү турында карар, шулай ук күрсәтелгән җир участогы төзелгән территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы һәм РФ ШтК 57.3 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән.;<br>2) Россия Федерациясенең бюджет законнарында, дәүләт хакимияте әгъзасы белән, Атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, Галәм эшчәнлеге буенча “Роскосмос” дәүләт корпорациясе, дәүләти бюджетныкы булмаган фондларның идарә әгъзалары яки җирле үзидарә әгъзалары белән билгеләнгән очракларда, бюджет инвестицяләрен гамәлгә ашырганда төзелгән, дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешүнамә булган очракта- күрсәтелгән килешүнамә, килешүнамә төзелгән хокукка ия булган кешенең җир бүлемтегенә хокукны раслаучы документлары; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көннән өч елдан да иртәрәк бирелмәгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, яисә линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән көннән алып өч елдан да соңга калмыйча, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштыру өчен, җир участогы таләп ителми торган, линияле объект төзелешенә рөхсәт биргән очракта территорияне планлаштыру проекты реквизитлары.<br>4) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм РФ ШтК 48 статьясындагы 15 өлеше нигезендә расланган проект документларындагы материаллар:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы, шулай ук линияле объектларга карата проект документациясен әзерләгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган проект (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);<br>в) архитектура һәм конструктив карарларны үз эченә алган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керү мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | карарлар һәм чаралар (Сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына, торак фонды объектларына карата проект документациясен әзерләү очрагында);<br>г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен төзү, башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булган очракта, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын да кертеп);<br>5) проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе ( РФ ШтК 48 ст. 12.1. бүлеге белән каралган, төзелешнең аерым этапларына кагылышлы), әгәр дә андый проект документларына, РФ ШтК 49 ст. белән туры килеп, экспертиза тиеш булса; РФ ШтК 49 ст.3.4. бүлеге белән каралган очракларда, проект документларына уңай дәүләт экспертиза бәяләмәсе;РФ ШтК 49 ст. 6 бүлеге белән каралган очракларда, проект документларына уңай дәүләт экспертиза бәяләмәсе;<br>6) Проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзасына нигезләнгән үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән, РФ ШтК 49 | |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертү очрагында, әлеге зат тарафыннан бу Кодекс нигезендә расланган проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган, проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең әлеге Кодексның 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;<br>7) РФ ШтК 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә эксперт ярдәме барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, башкарма хакимият органнарына яисә проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан тапшырылган, РФ ШтК 49 статьясындагы 3.9 өлешендә күрсәтелгән проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең таләпләргә туры килүен раслау;<br>8) рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт (төзүчегә РФ ШтК 40 статьясы нигезендә мондый рөхсәт бирелгән очракта);<br>9) капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корган очракта, мондый объектның барлык хокук ияләренең ризалыгы, әлеге Регламентның 2 бүлегендәге 2.5 п. п. 11 п. күрсәтелгән очраклардан тыш, күпфатирлы йортны үзгәртеп кору очраклары;<br>10) дәүләт (муниципаль) заказчы үткәргән очракта, дәүләт (муниципаль) унитар оешмасы, дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | (муниципаль) бюджет яки автономияле учреждениесе хокукка ия булып килгән, аңа карата әлеге әгъза мөлкәт хуҗасының хокукын яки оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган,дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектында реконструкцияне дәүләт хакимияте әгъзасы(әгъзасы), Атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, Галәм эшчәнлеге буенча “Роскосмос” дәүләт корпорациясе, дәүләти бюджетныкы булмаган фондларның идарә әгъзалары яки җирле үзидарә әгъзалары булып килгән әгъзалар башкарган очракта-реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгеләүче, шундый реконструкцияләүне үткәрү турында килешү;<br>11)күпфатирлы йортларны төзекләндерү очрагында, торак кануннары нигезендә кабул ителгән, күпфатирлы йортта бина һәм машина-урыны милекчеләренең гомуми җыелышында чыгарылган карар яки андый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең күләме кимү нәтиҗәсендә, күпфатирлы йортта бинаның һәм машина-урынының барлык милекчеләренең рөхсәте;<br>12) әгәр проект документларына дәүләти булмаган экспертиза бәяләмәсе тапшырылган очракта,проект документларына дәүләти булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән, юридик затның аккредитациясе турында таныклык күчермәсе. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 13) мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкарганда мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык характеристикалары һәм куркынычсызлыгы характеристикасы кагылса, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар;<br>14) Россия Федерациясе законнары нигезендә, аның урнашуы сәбәпле, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле яки аның нәтиҗәсендә реконструкцияләнгән объектка карата территорияне файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объектын төзегәндә яки элек билгеләнгән территориядән файдалану шартлары булган зона үзгәрергә тиешле капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта, территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаны билгеләү һәм үзгәртү турында карар күчермәсе;<br>15) территорияне комплекслы үстерүне мөстәкыйль гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгән очрактан тыш, капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, аңа карата җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән территорияне үстерү яки җирле үзидарә органы инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә башкару планлаштырылган очракта, төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә яки территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә | |

| | | |
|---|---|---|
| | күчермәсе.<br>1 – 8, 12, 14 һәм 15 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы белешмәләр), әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль тапшырмаган булса, Комитет тарафыннан дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмаларда соратып алына. | |
| | Хокукның күчеше турындагы белдерүдә киләсе реквизитлар күрсәтелергә тиеш:<br>1) җир кишәрлекләренә хокук күчү очрагында мондый җир кишәрлекләренә хокук бирүче документларның;<br>2) әгәр дә җир турындагы кануннар нигезендә, җир кишәрлекләрен оештыру турында карарны дәүләт хакимияте башкарма әгъзасы яисә җирле үзидарә әгъзасы кабул итсә, җир кишәрлекләрен оештыру турында карарлар; киләсе очракларда:<br>аңа карата яки берсенә карата төзү рөхсәтнамәсе бирелгән җир кишәрлекләрен кушу ысулы белән, җир кишәрлеген оештыру;<br>аңа карата яки берсенә карата төзү рөхсәтнамәсе бирелгән җир кишәрлекләрен бүлү, бүлешү яки бүлеп чыгару ысулы белән, җир кишәрлеген оештыру;<br>3) аларга карата төзү рөхсәтнамәсе бирелгән җир кишәрлекләрен бүлү, бүлешү яки бүлеп чыгару ысулы белән, җир кишәрлеген оештыру очрагында, капиталь | РФ ШтК 51 ст. п. 21.10 |

| | | |
|---|---|---|
| | төзелеш объектын төзергә, реконструкцияләргә планлаштырылган җир бүлемтегенең шәһәр төзелеше планының;<br>4) РФ ШтК 51 ст. 21.9 бүлеге белән каралган очракта, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне яңадан рәсмиләштерү карарларының. | |
| | Төзү рөхсәтнамәсен алу өчен кирәкле документлар, техник мөмкинлекләр булганда бары тик электрон формада гына тапшырыла:<br>әгәр дә проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе ( РФ ШтК 48 маддә 12.1. бүлеге белән каралган, төзелешнең аерым этапларына кагылышлы), әгәр дә андый проект документларына, РФ ШтК 49 маддәсе белән туры килеп, экспертиза тиеш булса; РФ ШтК 49 маддәсенең 3.4. бүлеге белән каралган очракларда, проект документларына уңай дәүләт экспертиза бәяләмәсе;РФ ШтК 49 маддәсенең 6 бүлеге белән каралган очракларда, проект документларына уңай дәүләт экспертиза бәяләмәсе электрон формада тапшырылган булса;<br>әгәр мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган, капиталь төзелеш объектының проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, ә шулай ук проект документларына дәүләт экспертизасы һәм (яки) инженерлык эзләнүләре | 729 нчы номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| | нәтиҗәләре үткәрү өчен башка кирәкле документлар электрон формада тапшырылган булса.<br>Төзелешкә рөхсәтнамә, төзелешкә рөхсәт бирү турында гаризада күрсәтелгән очракта, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.<br>Дәүләт хезмәтен алыр өчен гариза бланкын гариза бирүче шәхси Комитеттан алырга мөмкин.Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа кушылган документлар, гариза бирүче белән, кәгазьдә киләсе ысуллар белән тапшырыла алалар:<br>шәхси (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат белән);<br>почта аша, алу турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән.<br>Документлар, гариза бирүче белән, электрон имза белән расланып, шулай ук электрон рәвештә, "Интернет" челтәре мәгълүмат ресурслары яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша юнәлтелергә мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен | Электрон ведомствоара булышлык системасы буенча алынылар:<br>1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитутны билгеләү турында килешү, гавами сервитутны билгеләү турында карар, шулай ук күрсәтелгән җир участогы төзелгән территориянең | РФ ШтК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гаризачылар белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә;аларны бирү тәртибе. | кадастр планында җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы һәм РФ ШтК 57.3 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән.;<br>2) Россия Федерациясенең бюджет законнарында, дәүләт хакимияте әгъзасы белән, Атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, Галәм эшчәнлеге буенча “Роскосмос” дәүләт корпорациясе, дәүләти бюджетныкы булмаган фондларның идарә әгъзалары яки җирле үзидарә әгъзалары белән билгеләнгән очракларда, бюджет инвестицяләрен гамәлгә ашырганда төзелгән, дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешүнамә булган очракта- күрсәтелгән килешүнамә, килешүнамә төзелгән хокукка ия булган кешенең җир бүлемтегенә хокукны раслаучы документлары;<br>3) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көннән өч елдан да иртәрәк бирелмәгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, яисә линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән көннән алып өч елдан да соңга калмыйча, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштыру өчен, җир участогы таләп ителми торган, линияле объект төзелешенә рөхсәт биргән очракта территорияне планлаштыру проекты реквизитлары;<br>4) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм РФ ШтК 48 | |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясындагы 15 өлеше нигезендә расланган проект документларындагы материаллар:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы, шулай ук линияле объектларга карата проект документациясен әзерләгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган проект (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);<br>в) архитектура һәм конструктив карарларны үз эченә алган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керү мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (Сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына, торак фонды объектларына карата проект документациясен әзерләү очрагында);<br>г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен төзү, башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булган очракта, капиталь | |

| | | |
|---|---|---|
| | төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын да кертеп);<br><br>5) проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе ( РФ ШтК 48 ст. 12.1. бүлеге белән каралган, төзелешнең аерым этапларына кагылышлы), әгәр дә андый проект документларына, РФ ШтК 49 ст. белән туры килеп, экспертиза тиеш булса; РФ ШтК 49 ст.3.4. бүлеге белән каралган очракларда, проект документларына уңай дәүләт экспертиза бәяләмәсе;РФ ШтК 49 ст. 6 бүлеге белән каралган очракларда, проект документларына уңай дәүләт экспертиза бәяләмәсе;<br>проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзасына нигезләнгән үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән, РФ ШтК 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертү очрагында, әлеге зат тарафыннан бу Кодекс нигезендә расланган проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган, проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең әлеге Кодексның 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;<br>РФ ШтК 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә эксперт ярдәме барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, башкарма хакимият органнарына яисә проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан тапшырылган, РФ ШтК 49 | |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясындагы 3.9 өлешендә күрсәтелгән проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең таләпләргә туры килүен раслау;<br>6) рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт (төзүчегә РФ ШтК 40 маддәсе нигезендә мондый рөхсәт бирелгән очракта)<br>7) әгәр проект документларына дәүләти булмаган экспертиза бәяләмәсе тапшырылган очракта,проект документларына дәүләти булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән, юридик затның аккредитациясе турында таныклык күчермәсе;<br>8) Россия Федерациясе законнары нигезендә, аның урнашуы сәбәпле, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле яки аның нәтиҗәсендә реконструкцияләнгән объектка карата территорияне файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объектын төзегәндә яки элек билгеләнгән территориядән файдалану шартлары булган зона үзгәрергә тиешле капиталь төзелеш объектын реконструкциялəгән очракта, территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаны билгеләү һәм үзгәртү турында карар күчермәсе;<br>9) территорияне комплексы үстерүне мөстәкыйль гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгән очрактан тыш, капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, аңа карата җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән территорияне үстерү яки җирле | |

| | | |
|---|---|---|
| | үзидарә органы инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә башкару планлаштырылган очракта, төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә яки территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә күчермәсе. (Комитет тарафыннан күрсәтелгән документлар алар карамагында булган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан соратып алына)<br>Әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында юк икән, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар мөрәҗәгать итүче (төзүче) тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә.<br>Гаризачы бирергә хокуклы булган, документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе, әлеге Регламентның 2.5. пункты белән билгеләнде.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда булган, өстә күрсәтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүче, ведомствоара мәгълүмати булышлык системасы аша алына торган документларны, шәхси тапшырырга хокуклы.<br>Гариза бирүче белән күрсәтелгән документларны тапшырмау, дүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | нигез булып тормый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез юк | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | РФ ШтК 51 ст. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Түләү алынмый | РФ ШтК 51 ст. |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | 601 нче номерлы указ |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте һәм хезмәтләр күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада да, соратып алуны теркәү вакыты һәм тәртибе | Гариза кергән көнне.<br>Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көнендә кергән мөрәҗәгать, ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчү уңайлы).Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | 880 нче номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Комитет биналарының җәмәгать транспортына үтемлелек зонасында урнашуы;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарны инвалидлар өчен уңайлы итү;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы башка киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең | |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге , башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә мөрәҗәгать итүчене сайлау буенча (экстерриториаль принцип), Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт | ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Комитет белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында бу регламентны бозу турында нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Комитет белгечләре белән аралашу саны:<br>-дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхси тапшырганда - ике тапкырдан да артмау (консультацияләрне санамыйча) ;<br>-дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша яки электрон рәвештә тапшырганда – бердән дә артмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең Комитет (бүлек)яки КФҮ белгече белән хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул санда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирү күп функцияле үзәк, аның ераклашкан эш урыны аша гамәлгә ашырылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча яки комплекслы соратып алу составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү турында соратып алу юлы белән (комплексlы запрос ) | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация телефон аша шәхси яки электрон хәбәр формасында электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Интернет-кабул итү бүлмәсе аша) http://ojm.tatarstan.ru) бирелергә мөмкин.<br>Гаризаны һәм документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирү мөмкинлеге бар. | 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләр) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы

3.1.1.Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны тутырырга булышу.

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм рәсмиләштерү;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьләрне әзерләү һәм юнәлтү;

4) төзү рөхсәтнамәсен яки кире кагу турында хатны әзерләү;

5) гариза бирүчегә төзү рөхсәтнамәсен яки кире кагу турында хатны тапшыру;

6) техник хатаны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны тутыруда булышу.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алырга дип, шәхси, телефоннан һәм (яки) электрон почта аша, Бүлеккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече, гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итү формасы һәм башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булган очракта Бүлек белгече, дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларны тутырырга булыша.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу сораулары буенча консультация, документларны тутыру өлешендә булышлык.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче Комитетка шәхси, почта аша, электрон почта аша, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

3.3.2. Бүлек белгече:

гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза бирүче, хокуклы вәкил сыйфатында яки дәүләт хезмәтен алырга вәкаләтле зат сыйфатында килгән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

бу регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерә;

гаризаны гариза бирүчегә тапшыра яки почта аша, документларны кабул итү вакытын, теркәү номерын күрсәтеп, гаризаның күчермәсен җибәрә.

Бүлек белгече, төзүгә, (төзү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайтуга, төзү рөхсәтнамәсенә үзгәртүләр кертүгә) Рөхсәтнамә бирү турында гаризаларны теркәү Журналын алып бара ( алга таба - Журнал).

Журналда күрсәтелә:

Гариза бирүче белән документларны тапшыру вакыты ( Комитетка кергән датасы);

гариза бирүченең исеме;

документларны кабул иткән структур бүлекчәнең, вазыйфаи вәкаләтле затының фамилиясе һәм инициаллары;

кергән документларның объект исеме һәм битләр саны (папкалар, тартмалар һ.б.);

гариза бирүчегә төзү рөхсәтнамәсен (төзү рөхсәтнамәсен бирүдән баш тарту) тапшыру вакыты яки почта аша җибәрү вакыты;

төзү рөхсәтнамәсен (документларны кушып, төзү рөхсәтнамәсен бирүдән баш тарту) алган затның имзасы;

гариза бирүчегә төзү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайту турында белдерүне (Төзү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту) турында белдерүне тапшыру вакыты яки почта аша җибәрү вакыты;

гариза бирүчегә төзү рөхсәтнамәсенә үзгәрешләр кертү турында белдерүне (төзү рөхсәтнамәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында белдерүне тапшыру вакыты яки почта аша җибәрү вакыты;

Журнал, әлеге Реламентның 3 нче кушымтасы белән туры килеп, кулдан һәм электрон рәвештә алдып барыла.

Бүлек белгече кергән гариза турында мәгълүматны Журналга кертә.

3.3.1. һәм 3.3.2. пунктлары белән билгеләнгән процедуралар, гаризаны Комитетта теркәгән көнне башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен,кабул ителгән һәм теркәлгән документлар, Журналдагы язу.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьләрне әзерләү һәм юнәлтү.

3.4.1. Әлеге Регламентның 2.5. пункты белән каралган документларны тапшырган һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартырга нигез булмаган очракта, Бүлек белгече электрон рәвештә идарәара электрон мөнәсәбәт системасы аша, дәүләт хезмәтен күрсәтүче әгъзаларга, дәүләт әгъзалары карамагындагы муниципаль хезмәтләр күрсәтүче әгъзаларга яки җирле үзидарә әгъзаларына, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы оешмаларга, башка дәүләт әгъзаларына, җирле үзидарә әгъзаларына,әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән документлар буенча мәгълүмат алу өчен мөрәҗәгать итә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар, алдагы процедуралар тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә үтәләләр.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьләрне әзерләү һәм юнәлтү.

3.4.2. Мәгълүматларны бирүче белгечләр, ведомствоара электрон мөнәсәбәт системасы аша кергән сораулар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматларны) тапшыралар яки дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның( мәгълүматларның) булмавы турында белдерү юнәлтәләр.

Ведомствоара электрон мөнәсәбәт процесында катнашучы әгъзалар, кануннар белән билгеләнгән вакытта, әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән документларны тапшыралар.

Процедуралар нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән документлар яки кире кагу хаты.

3.5.Төзү Рөхсәтнамәсен яки кире кагу турында хатны әзерләү;

3.5.1. Бүлек белгече:

документларны, бу регламентның 2.5. пунктына туры килүенә тикшерә;

Бүлек белгече гариза бирүчедән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларыннан кергән документлар нигезендә:

төзү Рөхсәтнамәсе бланкын тутыра яки төзү Рөхсәтнамәсе бирмәү турында хат әзерли;

тутырылган объектны файдалануга кертүгә Рөхсәтнамә бланкын яки объектны файдалануга кертүгә Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны Бүлек башлыгына раштыруга җибәрә.

Рөхсәтнамә бирүдән баш тарту түбәндәге нигезләрнең берсе булганда әзерләнә:

1) капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү турында гариза биргәндә-РФ ШтК 51 статьясындагы 7 өлешендә каралган документларның булмавы;

2) тапшырылган документларның капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу өчен бирелгән көнгә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, яки линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш) туры килмәү очрагында, ә шулай ук җир участогыннан файдалануга рөхсәт ителгән һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә, рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкциянең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

РФ ШтК 51 статьясындагы 7.1 өлеше нигезендә соратып алынган документларны алмау яки вакытында алмау төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез була алмый. РФ ШтК 51 статьясындагы 11.1 өлешендә каралган очракта, мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органыннан кергән, капиталь төзелеш объектының проект документлары бүлегенең тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының архитектур чишелешләренә карата, федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата, шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында нәтиҗәсе, рөхсәтнамә бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән территорияне үстерү яки җирле үзидарә органы инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территориядә планлаштырылган очракта, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен шулай ук төзелгән территорияне үстерү турындагы шартнамә яки территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә нигезендә расланган территорияне планлаштыру буенча документациянең булмавы (территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән очрактан тыш) нигез булып тора.

Төзелешкә Рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза биргәндә:

әгәр дә капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, аңа капиталь ремонт ясау мондый гариза бирү срогы чыкканчы башланмаган булса.

Төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр керткәндә:

1) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар турында белешмәләр булмаган очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ булмау яки төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта, мондый рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, РФ ШтК 51 статьясындагы 7 өлешендә каралган документлар булмау;

2) җир кишәрлегенә, җир асты байлыкларыннан файдалану, җир кишәрлеген оештыру турында хокук күчү хәбәрнамәсендә күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес булмавы;

3) РФ ШтК 51 статьясындагы 21.7 өлешендә каралган очракта, Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә, рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән файдалану һәм (яки) чикләүләр буенча шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәтнамә бирү датасына билгеләнгән таләпләрнең урнаштыру планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә куелган таләпләргә туры килмәве.

4) җир кишәрлегенә, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы, җир кишәрлеген оештыру турында хокуклар күчү турындагы белдерүдә РФ ШтК 51 статьясындагы 21.10 өлешенең 1-4 пунктларында каралган документлар реквизитлары булмау яки РФ ШтК 51 статьясындагы 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ булмау;

5) рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта,урнаштыру планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәт алу яки җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү өчен тәкъдим ителгән көнгә билгеләнгән, капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата куелган таләпләргә туры килмәве.

Төзелеш өчен рөхсәтнамә алынганнан соң бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәтамәгә үзгәрешләр кертү өчен бирелгән очракта, мондый шәһәр төзелеше планы төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турында гариза җибәргәнчегә кадәр 3 (өч) елдан артыграк булмаска тиеш;

6) планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектының, рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, РФ ШтК 51 статьясындагы 21.7 өлешендә каралган очракта яки төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта, Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм төзелеш өчен рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән көнгә

гамәлдә булган, җир кишәрлегеннән файдалану һәм (яки) чикләүләргә туры килмәве;

7) Дәүләт төзелеш күзәтчелеге кысаларында ачыкланган, рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турында гариза бирү көненә төзелеш, реконструкция эшләре башланмаган булу факты турында Комитетта мәгълүмат булу яки әгәр төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәнең гамәлдә булу вакытын озайту белән бәйле булган очракта, мондый хәбәр җибәрү РФ ШтК 52 статьясындагы 5 өлеше таләпләре нигезендә мәҗбүри булып торса, әлеге эшләр башлану турында хәбәрнең булмавы турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органыннан мәгълүмат керү.

8) җир кишәрлегенә, җир асты байлыкларыннан файдалану, җир участогын төзү турында хокук күчү турындагы белдерү кәгазендә РФ ШтК 51 статьясындагы 21.10 өлешенең 1-4 пунктларында каралган документлар реквизитлары булмау;

9) төзелешкә бирелгән рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы ун эш көненнән дә ким булган вакыт эчендә үзгәрешләр кертү турында гариза бирү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге регламентта каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәтнамә яки төзелешкә рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрелгән хат.

3.5.2. Бүлек башлыгы төзү Рөхсәтнамәсе бланкын яки төзү Рөхсәтнамәсе бирмәү турында хатны яраштыра һәм аларны Комитет рәисенә имза куярга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедура, Регламент белән каралган, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көнендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имза куярга җибәрелгән төзү Рөхсәтнамәсе бланкы яки төзү Рөхсәтнамәсе бирмәү турында хат.

3.5.3. Комитет рәисе төзү Рөхсәтнамәсен яки төзү Рөхсәтнамәсен бирмәү турында хатка имза куя һәм аны кире Бүлеккә кайтара.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар, Регламент белән каралган, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көнендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: имза куелган төзү Рөхсәтнамәсе яки объектны төзү Рөхсәтнамәсен бирмәү турында хат.

3.6. Төзү Рөхсәтнамәсе яки төзү Рөхсәтнамәсе бирмәү турында хатны тыпшыру.

3.6.1. Бүлек белегече төзү Рөхсәтнамәсе бирелгән рөхсәтнамәләр Реестрында терки (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы) яки төзү Рөхсәтнамәсе бирмәү турында хатны гариза бирүчегә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедура, Комитет рәисе белән төзү Рөхсәтнамәсенә яки төзү Рөхсәтнамәсен бирмәү турында хатка имза куйган көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәтнамәләр Реестрында теркәлгән төзү Рөхсәтнамәсе яки төзү Рөхсәтнамәсе бирмәү турында хат.

3.6.2. Бүлек белгече, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулы белән, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе турында гариза бирүчегә (аның вәкаләтле затына) хәбәр итә, рәсмиләштерелгән төзү рөхсәтнамәсе (төзү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайту) бирү датасын һәм вакытын әйтә;

төзү Рөхсәтнамәсен бирү (төзү Рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайту) турында карарны Журналда терки.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар, Регламент белән каралган, алдагы процедура тәмамланган көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Журналда теркәлгән, төзү Рөхсәтнамәсе бирү (төзү Рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайту) турында карар, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе турында гариза бирүчегә (аның вәкаләтле затына) хәбәр итү.

3.6.2. Бүлек белгече гариза бирүчегә (аның вәкаләтле затына) төзү рөхсәтнамәләре журналында, алу турында имза астына төзү Рөхсәтнамәсен (төзү/реконструкцияләү рөхсәтнамәсенең гамәлдә булу вакытын озайту) тапшыра.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар, гариза бирүче килгән көнне 15 минут эчендә үтәләләр.

Процедура нәтиҗәсе: төзүгә бирелгән Рөхсәтнамә.

3.7. Техник хатаны төзәтү:

төзү Рөхсәтнамәсен яңадан төзү, элек бирелгән төзү Рөхсәтнамәсендә җибәрелгән, техник хатаны төзәтү (хәреф хатасы яки арифметик хата) белән бәйле рәвештә үтәлә.

Төзү Рөхсәтнамәсен яңадан ясау, техник хатаны төзәтү турында теркәлгән гариза (гаризаның формасы бу регламентның 5 нче кушамтасында бирелде) һәм аңа кушылган хаталы төзү Рөхсәтнамәсе нигезендә үтәлә.

3.7.1. Бүлек белгече:

- гаризаны кабул итә һәм терки;

- гариза бирүчегә,документларны кабул итү вакытын һәм бирелгән номеры күрсәтеп, гаризаның күчермәсен тапшыра яки почта яки электрон почта аша( аның теләве буенча) юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза теркәлгән көнне башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза

3.7.2. Бүлек белгече:

- төзү рөхсәтнамәсен яңадан ясый;

- төзү рөхсәтнамәсен яңадан ясау турында гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза кергән көнне башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына яраштыру өчен юнәлтелгән төзү Рөхсәтнамәсе һәм гариза бирүчегә хат проекты.

3.7.3. Бүлек башлыгы әзерләнгән төзү Рөхсәтнамәсенең дөреслеген тикшерә, хат проектын яраштыра һәм аларны Комитет рәисенә юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, Бүлек башлыгына яраштырырга юнәлтелгән төзү Рөхсәтнамәсе һәм хат проекты кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имза куярга юнәлтелгән төзү Рөхсәтнамәсе һәм хат проекты.

3.7.4. Комитет рәисе хат проектын һәм аңа куелган төзү Рөхсәтнамәсенә кул куя һәм Бүлеккә юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, Бүлек башлыгыннан хат

проекты кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: яраштырылган хат проекты һәм төзү Рөхсәтнамәсе.

3.7.5. Бүлек белгече, Комитет рәисе белән кул куелган, дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы хатны рәсмиләштерә, һәм төзү Рөхсәтнамәсе белән бергә гариза бирүчегә яки аның вәкаләтле затына(ышанычнамә булса) имза астына тапшыра.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, гариза бирүче яки аның вәкаләтле заты килгәннән соң, бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган хат һәм техник хаталары төзәтелгән төзү Рөхсәтнамәсе.

## 4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү, тикшерүләр уздыруны, урындагы затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьле гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карар кабул итүне һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне саклау артыннан тикшерү формалары:

эш башкаруны алып бару;

каралган документларның нәтиҗәсе закон таләпләренә туры килүе (әлеге Регламентның);

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, аның нәтиҗәсен бирү вакытын һәм тәртибен саклау.

Тикшерүләрне уздыруның кабатлануы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) характер йөртә.

4.2.Тикшерүләрне уздыру нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыклаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, законнар белән каралган тәртиптә, җаваплылыкка тарттырылалар.

4.3. Гариза бирүчеләр ягыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү,

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Комитетныэ ачык эшчәнлегендә, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлегендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, ә шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган

**(кылмаган) гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Бүлек белгече, Бүлек башлыгы, Комитетның район хезмәткәрләре гамәлләрен (гамьсезлеген) судка кадәрге тәртиптә, Комитет рәисенә шикаять кылу хокукына ия. Комитет рәисе белән кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамьсезлегенә) шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылу;

3)дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп итү;

4)гариза бирүчедән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тартуның нигезләре федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәргән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын һәм тәртибен бозу;

9) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул иткән вакытта документларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматларны таләп итү яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.4.Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

Комитетның исеме, гамәлләренә (гамьсезленегә) шикаять бирелә торган,

Комитетның дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи заты, дәүләт хезмәткәре исеме, фамилиясе, атасының исеме;

гариза бирүче-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гариза бирүче –юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, һәм шулай ук гаризачыга җавап бирү өчен элемтә телефонының номеры (номерлары), (булган очракта) электрон почта һәм почта адресы (адреслары);

Комитет, аның вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче алар нигезендә Комитетның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәл кылмавы (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләре.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә. Комитет, Комитетның вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканга шикаять белдергән очракта яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылганда -аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1)шикаять, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозылу яисә җинаять кылу билгеләре ачыкланса, шикаятьне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи зат кичекмәстән бар булган материалларны прокуратура органнарына юнәлтә.

5.9. Комитет карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук

аның вазыйфаи затларына, яки дәүләт хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән: ___________________________________________
(төзергә, реконструкцияләргә җыенучы
_____________________________________________
юридик затның исеме;
______________________________________________
ИНН; юридик һәм почта адресы,
____________________________________________
җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме;
______________________________________________
телефон; банк реквизитлары (банкның исеме,
______________________________________________
р/с, к/с, **БИК**)

## Капиталь төзелеш объектын төзүгә/реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү турында гариза.

Адрес буенча җир бүлемтегендә: ____________________________________________________
(шәһәр, район, урам, бүлемтек номеры)
_____________________________________________________________________ай вакытка
_________________________________________________________________________________
(кирәклесенең астына сызарга), (объектның исеме)
капиталь төзелеш объектын төзү/реконструкцияләү рөхсәтнамәсен бирүегезне сорыйм .

Төзү/реконструкцияләү киләсе документ нигезендә алып барылачак_____
______________________________________ «_____» ________________ елдан № _______.
(документ исеме)
Җир белән куллану хокукы беркетелде _______________________________________
______________________________________ «_____» ________________елдан № ________.
(документ исеме)
Проект эшләрен башкарырга хокукы, киләсе документ белән беркетелгән_____
________________________________________________________________________________
(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме)
«_____» _______________елдан № _______, объектны төзүгә проект документлары эшкәртелде______________________________________________________________________
(проект ясаучы оешманың исеме, ИНН, юридик һәм почта адресы,
_________________________________________________________________________________
җитәксенең исеме, фамилиясе, атасының исеме, телефон номеры, банк реквизитлары)
________________________________________________________________________________
(банк исеме, р/с, к/с, **БИК**))
һәм билгеләнгән тәртиптә кызыксынган оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзү әгъзалары

белән яраштырылды:

- дәүләт экспертизасының уңый бәяләмәсе алынды № ____ «_____» ___________елдан

- җир бүлемтегенең оештыру планының схемасы яраштырылды _______________

_____________________________________________________№ _____«____» _________елдан.

(оешма исеме)

Проект документлары расланды ___________________________________________

____________________________________ № ________ «_____» ___________________ елдан

Өстәмә хәбәр итәбез:

Йорт төзүче белән төзелешне (реконструкцияне) финанслау башкарылды___________

________________________________________________________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры )

Эшләр «______» _____________________ елдан № ________ килешүнамә нигезендә подрядчы (хуҗалык)ысулы белән алып барылачак ____________________________________

________________________________________________________________________________

(оешманың исеме, ИНН; юридик һәм почта адресы,

________________________________________________________________________________

җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме; телефон; банк реквизитлары (банкның

________________________________________________________________________________

исеме,р/с, к/с, **БИК**)

Төзү-монтаж эшләрен үтәү хокукы беркетелгән ______________________________________

________________________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле әгъзаның исеме)

___________________________________ «______» _________елдан № _______.

Эшләрне җитештерүче белән ______________________ «____» ________________ елдан № _______ боерык белән, махсус _______________белемле һәм төзүдә _________ ел эш

( югары, урта)

стажы булган________________________________________________________ билгеләнде.

(вазыйфа, фамилия, исем, атасының исеме)

Төзелешне тикшерү «______» _________елдан № _______ килешүнамә белән тәңгәл килеп,___________________________________________________________________________

(Оешманың исеме, ИНН; юридик һәм почта адресы,

________________________________________________________________________________

җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме; телефон; банк реквизитлары (банкның

________________________________________________________________________________

исеме,р/с, к/с, **БИК**)

белән башкарылачак.

Заказ бирүченең (йорт төзүченең) функцияләрен үтәү хокукы ____________________

________________________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле әгъзаның исеме)

«_____» ________________ елдан № _______ документ нигезендә беркетелде.

Әлеге гаризада күрсәтелгән барлык мәгълүматлар белән бәйле үзгәрешләр турында,

________________________________________________________________________________

(вәкаләтле әгъзаның исеме)

хәбәр итәргә вәгъдә бирәм.

___________________ ___________________ _______________________________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

«______» ______________________ ел

М.П.

Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 2нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән: ________________________________________
(төзергә, реконструкцияләргә җыенучы
____________________________________________
юридик затның исеме;
____________________________________________
ИНН; юридик һәм почта адресы,
__________________________________________
җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме;
____________________________________________
телефон; банк реквизитлары (банкның исеме,
____________________________________________
р/с, к/с, **БИК**)

## Капиталь төзелеш объектын төзүгә/реконструкцияләүгә бирелгән рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза.

Адрес буенча җир бүлемтегендә: _________________________________________________
(шәһәр, район, урам, бүлемтек номеры)
_________________________________________________________________ай вакытка
___________________________________________________________________________
(кирәклесенең астына сызарга), (объектның исеме)
«_____»__________ елдан № ______ капиталь төзелеш объектын төзүгә/реконструкцияләүгә бирелгән рөхсәтнамәнең гамәлдә булу вакытын озайтуыгызны сорыйм .

Төзү/реконструкцияләү киләсе документ нигезендә алып барыла________________
____________________________________ «_____» _______________ елдан № _______.
(документ исеме)

Җир белән куллану хокукы беркетелде _____________________________________
____________________________________ «_____» _______________елдан № ________.
(документ исеме)

Проект эшләрен башкарырга хокукы, киләсе документ белән беркетелгән_____
___________________________________________________________________________
(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме)
«_____» ______________елдан № _______, объектны төзүгә проект документлары эшкәртелде_________________________________________________________________
(проект ясаучы оешманың исеме, ИНН, юридик һәм почта адресы,
___________________________________________________________________________
җитәксенең исеме, фамилиясе, атасының исеме, телефон номеры, банк реквизитлары)
___________________________________________________________________________
(банк исеме, р/с, к/с, **БИК**))

һәм билгеләнгән тәртиптә кызыксынган оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзү әгъзалары

белән яраштырылды:

- дәүләт экспертизасының уңый бәяләмәсе алынды № ____ «_____» ___________елдан
- җир бүлемтегенең оештыру планының схемасы яраштырылды _______________

______________________________________________________№ _____«____» _________елдан.

(оешма исеме)

Проект документлары расланды ___________________________________________

_____________________________________ № ________ «_____» ____________________ елдан

Өстәмә хәбәр итәбез:

Йорт төзүче белән төзелешне (реконструкцияне) финанслау башкарылды___________

_____________________________________________________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры )

Эшләр «______» _____________________ елдан № ________ килешүнамә нигезендә подрядчы (хуҗалык)ысулы белән алып барылачак _____________________________________

_____________________________________________________________________________

(оешманың исеме, ИНН; юридик һәм почта адресы,

_____________________________________________________________________________

җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме; телефон; банк реквизитлары (банкның

_____________________________________________________________________________

исеме,р/с, к/с, **БИК**)

Төзү-монтаж эшләрен үтәү хокукы беркетелгән ______________________________________

_____________________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле әгъзаның исеме)

_______________________________________ «______» _________елдан № _______.

Эшләрне җитештерүче белән ______________________ «____» ________________ елдан № _______ боерык белән, махсус _______________белемле һәм төзүдә _________ ел эш

( югары, урта)

стажы булган_________________________________________________________ билгеләнде.

(вазыйфа, фамилия, исем, атасының исеме)

Төзелешне тикшерү «______» _________елдан № _______ килешүнамә белән тәңгәл килеп,___________________________________________________________________

(Оешманың исеме, ИНН; юридик һәм почта адресы,

_____________________________________________________________________________

җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме; телефон; банк реквизитлары (банкның

____________________________________________________________________________-

исеме,р/с, к/с, **БИК**)

белән башкарылачак.

Заказ бирүченең (йорт төзүченең) функцияләрен үтәү хокукы _____________________

_____________________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле әгъзаның исеме)

«_____» ________________ елдан № _______ документ нигезендә беркетелде.

Әлеге гаризада күрсәтелгән барлык мәгълүматлар белән бәйле үзгәрешләр турында,

_____________________________________________________________________________

(вәкаләтле әгъзаның исеме)

хәбәр итәргә вәгъдә бирәм.

___________________ ___________________ _______________________________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

«______» ______________________ ел

М.П.

Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 3 нче кушымта

**Төзү рөхсәтнамәсен бирү ( төзүгә бирелгән рөхсәтнамәнең гамәлдә булу вакытын озайту) турындагы гаризаларны теркәү журналы**

| № | Гариза бирүче белән документларны бирү датасы (документларны Комитетта теркәү датасы) | Гариза бирүченең исеме ( хокук күчү турындагы белешмәдә күрсәтелгән зат) | Объектның атамасы | Төзелешкә рөхсәтнамә әзерләү датасы | Гариза бирүчегә төзелешкә рөхсәтнамә бирү (төзелешкә рөхсәтнамә бирүдән баш тарту) яки почта аша җибәрү датасы | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә(төзелешкә рөхсәтнамә бирүдән баш тарту) алган затның имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 4 нче кушымта

**Капиталь төзелеш объектларын төзүгә бирелгән рөхсәтнамәләр реестры**

| № | Кергән документның номеры һәм датасы | Гариза бирүченең исеме | Объектның атамасы | Рөхсәтнаменең номеры һәм датасы | Рөхсәтнаменең гамәлдә булу срогы | Чыга торган документның номеры һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 5 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән: ______________________________________
(төзергә, реконструкцияләргә җыенучы
__________________________________________
юридик затның исеме;
__________________________________________ ИНН;
юридик һәм почта адресы,
_______________________________________
җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме;
__________________________________________
телефон; банк реквизитлары (банкның исеме,
__________________________________________
р/с, к/с, **БИК**)

**Техник хатаны төзәтү турында гариза.**

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

______________________________________________________________________________
(хезмәтнең атамасы)

Язылган_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:
_____________________________________________________________________________.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм ул үзгәрешләрне документка кертүегезне сорыйм.

Киләсе документларны теркім:

1. ________________________________________________________________
2. ________________________________________________________________
3. ________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хаталар) төзүтүгә бирелгән гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, андый карарны электрон документ рәвешендә, киләсе электрон почтага җибәрүегезне сорыйм: ____________________________________________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазь ияддә, почта аша, киләсе адрес буенча:
_____________________________________________________________________________.

Минем гаризада бирелгән шәхси мәгълүматларым, ә шулай ук минем белән

аста язылган мәгълүматлар дөрес булуын раслыйм.

Гаризага өстәлеп бирелгән документлар (документларның күчермәләре), Россия Федерациясе кануннары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшырган вакытта, бу документлар гамәлдә һәм андагы мәгълүматлар дөрес.

__________________ _______________________ (__________________________)

(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына кушымта (белешмә өчен)

**Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә, төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аны башкаруны тикшерүче вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты**

| Вазыйфа | Гражданнарны кабул итү көннәре һәм вакыты | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Комитет рәисе | Сишәмбе сәг.14.00 язылу буенча | 211-66-99 | ojm@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | Пәнҗешәмбе 14.00-18.00 | 211-75-06 | Ramil.Sharafutdinov0@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | Дүшәмбе 14.00-18.00 | 211-68-62 | Rinat.Chispyakov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | | 211-68-62 | Roza.Minnegulova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |